ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.02.2022 г.Лениногорск № 82

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча шәһәр җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен муниципаль район дәрәҗәсенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә һәм Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең вәкаләтләрен «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру максатчанлыгы белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенә «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге дәрәҗәсенә җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны - ритуаль хезмәтләр оештыруны тапшырырга.
2. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең әлеге карарының 1 пунктында каралган вәкаләтләрнең бер өлешен «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге дәрәҗәсенә тапшыру турында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча кушымтада бирелгән Килешүне расларга.
3. Әлеге карарны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советына карау өчен җибәрергә.
4. Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен Лениногорск муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 календарь көннән дә артмаган срокка тапшыру турында килешү төзү буенча як булып торырга.

5. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында, рәсми публикаторда һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры                                        Р.Г. Хөсәенов

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 25 февралендәге 82 номерлы карары белән расланды

**Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча шәһәр җирлеге вәкаләтләрен муниципаль район дәрәҗәсенә тапшыру турында килешү**

Лениногорск шәһәре «___» _______ 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының __ номерлы карары нигезендә, Лениногорск муниципаль берәмлеге Башкарма комитет, Нигезләмә нигезендә эш итүче җитәкчесе Р.Р. Сытдиков һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты, Нигезләмә нигезендә эш итүче җитәкчесе З.Г. Михайлова түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

**1 бүлек.**

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тапшыра, ә «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 22 пунктында каралган ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру вәкаләтләре өлешендә үтәлүгә кабул итә.

**2 бүлек.**

Төзелгән килешү нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бюджетына Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бюджетыннан бирелә торган акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

**3 бүлек.**

Тапшырыла торган акчалар күләме, әлеге килешүнең 1 бүлегендә санап үтелгән вәкаләтләрне өлешчә яки тулы һәм үз вакытында үтәү өчен кирәкле чараларның фаразланган күләменнән чыгып, яклар тарафыннан билгеләнә.

**4 бүлек.**

«Лениногорск шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматларны (мәгълүматны) тапшырырга йөкләнә.

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзенә тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен финанс чаралары белән тәэмин ителгән дәрәҗәдә җаваплылык тота.

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе финанс елы тәмамланганнан соң 10 (ун) календарь көннән дә соңга калмыйча Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә узган финанс елында тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлеше турында хисап җибәрә.

**5 бүлек.**

Тапшырыла торган средстволарны вакытында күчермәгән очракта, муниципаль берәмлек Башкарма комитеты җитәкчесе Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәхси счетыннан «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге рефинанслау ставкасы күләмендә «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бюджеты керемен
ә вакытыннан элек һәр көн өчен күчерелә торган рефинанслау ставкасы күләмендә пени алына.

Йөкләмәләрне вакытында һәм (яки) тулы булмаган үтәмәгән очракта, гаепле муниципаль берәмлек (район, авыл җирлеге) тапшырыла торган акчаларның айлык күләменнән 0,1% күләмендә неустойка түли.

**6 бүлек.**

Әлеге Килешү Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында, рәсми публикаторда һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Әлеге килешүнең гамәлдә булу срогы 2025 елның 1 сентябренә кадәр билгеләнә.

Әлеге килешү, әгәр якларның берсе дә аның гамәлдә булу срогы тәмамланганчы бер ай кала, аны туктату яки үзгәртү турында белдермәсә, йә яңа

килешү төзү турында белдермәсә, шул ук вакытка һәм шул ук шартларда озайтылган дип санала.

**7 бүлек.**

Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- якларның килешүе буенча;
- район Башкарма комитеты тарафыннан әлеге килешүнең 1 бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашырмау яки тиешенчә башкармау.

Әлеге килешүне вакытыннан алда берьяклы тәртиптә өзгән очракта, өзү инициаторы як бу хакта, сәбәпләрен күрсәтеп, өзелү көненә кадәр 30 көн кала, язма рәвештә, башка якка хәбәр итә.

Әлеге килешүнең гамәлдә булуы берьяклы тәртиптә түбәндәге очракларда туктатылырга мөмкин:

- Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарын үзгәртү;
- бер як тарафыннан үз йөкләмәләрен системалы (3 айдан артык) үтәмәү;
- әгәр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкин булмаса, яки килеп туган шартларда әлеге вәкаләтләр шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Яклар арасындагы бәхәсләр булганда әлеге Килешү суд тәртибендә өзелергә мөмкин.

**8 бүлек.**

Әлеге килешү бер үк юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде.

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе

_________________ З.Г.Михайлова
(имза)
М. У.

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе

___________________ Р.Р.Сытдиков
(имза)
М. У.